Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

15 февраль 2022 ел № 123

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Башкарма комитетның 2021 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында отчеты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителгән отчетны карап,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Башкарма комитетның 2021 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында отчетын игътибарга алырга.

2. Башкарма комитетка 2022 елга беренче чиратта түбәндәге бурычларны билгеләргә:

- Әлмәт муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен, федераль, республика һәм муниципаль программаларны, милли проектларны тормышка ашыруны тәэмин итү;
- юл-урам челтәрен комплекслы модернизацияләү, җәмәгать киңлекләрен һәм квартал эчендәге территорияләрне төзекләндерү буенча чаралар үткәрү;
- һавага һәм су ресурсларына тискәре йогынтыны киметү өлкәсендә экологик чараларны тормышка ашыру;
- муниципаль маршрутларда пассажирлар йөртү сыйфатын арттыру, шәһәр маршрутларында пассажирлар ташу транспорт паркының гомуми күләмендә электр транспорты өлешен арттыру;
- гомуми белем бирү учреждениеләре челтәрен үстерү, мәктәп тукланыуын яхшырту буенча чараларны гамәлгә ашыру;
- мәгариф, сәламәтлек саклау өлкәләрендә муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын һәм һәркем куллана алырлык булуын арттыру буенча чараларны тормышка ашыру;
- газ кертелмәгән шәһәр һәм авыл массивларындагы шәхси хуҗалыкларны газ белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру буенча чараларны гамәлгә ашыру.

3. Район Башкарма комитетына хисапны Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар, социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов